ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МЮД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАР

№ 17 11.02.2021

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 22 июнь, 61 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге территориясендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 ел, 22 июнь, 61 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.3. Җирлек Советы тарафыннан үткәрелгән иҗтимагый фикер алышуларның яки гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә әзерләнгән җирлек Советы карары проекты җирлек советының чираттагы утырышы көн тәртибенә кертелә»

1.2. 12.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.6. Җирлек Советы, җирлек башлыгының иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә әзерләнгән карары, билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә халыкка җиткерелергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Мюд авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы порталында(http://aksubayevo.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе: Т.В. Зюзина